ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

08.05.2018 г. Иннополис № 29

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгына багышланган тантаналы чараларны оештыру һәм уздыру турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында совет халкының җиңүен мәңгеләштерү турында» 1995 елның 19 маендагы 80 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 73 еллыгына багышланган тантаналы чаралар үткәрүгә әзерлек максатларында, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгына багышланган тантаналы чаралар оештыру һәм уздыру турында» 2017 елның 04 маендагы 27 номерлы Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - 27 номерлы карары):
   1.1. Чараны үткәрүгә чыгымнар сметасын яңа редакциядә расларга (1-нче кушымта).
   1.2. 27 нче карарның 1 кушымтаның 3нче пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:
      «3. 13:25 Чарада катнашучылар өчен кыр кухнясы эше һәм фотосессия.»
2. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Югары

Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре
Башкарма комитетының
№____ "__" ______________
2018 ел карарына
1 нче кушымта

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73 еллыгына багышланган тантаналы чаралар үткәрүгә чыгымнар сметасы.

| № | Чыгымнар исеме | Күләме/дanə | Бәясе бер. сум. | Гомуми бәя, сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Пироттехник тамаша оештыру | | | 70 000,00 |
| 1.1 | Салют батареясы. Калибр 30мм. Атыш - 54шт. | 2 данә | 5 000,00 | 10 000,00 |
| 1.2 | Салют батареясы зур калибрлы. Калибр 50мм. Атышлар - 25 данә. | 2 данә | 12 000,00 | 24 000,00 |
| 1.3 | Салют батареясы веерлы. Калибр 30 мм. Атыш - 5 данә. | 6 данә | 1 500,00 | 9 000,00 |
| 1.4 | Салют батареясы. Калибр 30 мм. 160 данә ату | 1 данә | 12 000,00 | 12 000,00 |
| 1.5 | Салют батареясы зур калибрлы. Калибр 50 мм. Атыш - 40 данә. | 1 данә | 15 000,00 | 15 000,00 |
| 2. | Кайнар туклану оешмалары - «Кыр кухнясы». | 200 порция | 235,00 | 47 000,00 |
| 3. | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чараны оештыру. | | | 99 000,00 |
| 3.1 | Тынлы оркестр | 1 хезмәт күрсәтү | 40 000, 00 | 40 000,00 |
| 3.2 | Тавыш операторы хезмәтләре. | 2 сәгать | 4 000,00 | 8 000,00 |
| 3.3 | Чара үткәрү чорында тавышны тоташтыру һәм аңа ярдәм итү өчен электр генераторы бирү хезмәтләре күрсәтү. | 2 сәгать | 2 000,00 | 4 000,00 |
| 3.4 | Чара дәвамында алып баручы хезмәтләре | 2 сәгать | 6 000, 00 | 12 000,00 |
| 3.5 | Басма өчен макетлар версткасы хезмәте (фото, эшкәртмичә + текст) һәм А4 форматындагы табличкалар (ябыштырылган пластик) бирү.<br>1 м озынлыктагы фото өчен пластик тоткычлар. | 200 данә | 175, 00 | 35 000, 00 |
| | Нәтиҗә: | | | 216 000,00 |